СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2025 г. Заинск № 12

**2025 һәм 2026 елларда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 һәм 2026 елларда эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми дип билгеләргә.
2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куелганда әлеге карарның 1 пункты кулланылмый.
3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары И.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**